ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
“АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ“
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН»

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423052,Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, с. Сунчелеево, ул.Ленина, 76.
Тел. (8-84344-4-98-24) ОГРН 1061665002080,
ОКПО 94318582, ИНН/КПП 1603004776/160301001

**КАРАР**

**№13** **22.10.2025 ел**

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Башкарма комитеты "Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 20.09.2024 елгы №8 карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 31.07.2025 елгы 304-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясындагы 3 пунктының г, д пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАРы:

1.Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Башкарма комитеты 20.09.2024 № 8 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк" сүзләрен "мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк"сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктында түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчасы өстәргә::

"4.1)Мөрәҗәгать итүче булмаган затның персональ белешмәләре бирелгән очракта, федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү өчен ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасы аша мондый затның яисә аның шәхси белешмәләр эшкәртүгә законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда ризалыгын алу таләп ителми.""

2.Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтына (http://aksubaevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сөнчәле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: А.В.Калуков